**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОИГЛАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Иглай ав. **КАРАР**

**№ 26** «23» сентябрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыннары турында» 2023 елның 03 апрелендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә «Яктырткыч җайланмалар, электр лампалары, тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау өлешендә һәм аларны урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булганда җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында (2024 елның 14 мартына үзгәрешләр белән)», Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларның туплану урыннары турында» 2023 елның 03 апрелендәге 4 номерлы карарының 2 пунктына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай территориясендә, әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру, шулай ук мәгълүматны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында (стойкаларда) урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында: http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Техник хата җибәрелү сәбәпле 2025 елның 25 августындагы 25 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе М.И. Хәмидуллин